ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_16.12.2019 г._____ М ө с л и м _769___

**2020 елга торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү буенча тарифларны раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкка күрсәтелә торган торак һәм коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту һәм алар өчен түләү күләмен нигезләү чаралары турында» 2010 елның 09 апрелендәге 250 номерлы карары, «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халыкның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 19 февралендәге 85 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 3 декабрендәге 1097 номерлы карары нигезендә, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Торак урыннан файдаланган өчен түләү күләмен (наем өчен түләү), социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча яллаучылар өчен торак урыннарны карап тоткан өчен түләү, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Муниципаль торак фондының торак урыныннан файдаланган өчен түләү күләмен (наемга алынган өчен түләү) 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Авыл Утлары» - «Сельские Огни» район газетасында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.Х.Әхмәтов

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
«___» ___________ 2019 ел,
_____ номерлы карарына
1 нче кушымта

Торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү) түләү күләме, социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча яллаучылар өчен торак урыннарны карап токкан өчен түләү һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләме

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Түләү күләме, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Торак фонд белән идарә итү | айга торак бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. өчен | 1,56 |
| 2 | Капиталь ремонт (торак милекчеләреннән алына) | айга торак бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. өчен | 6,11 |
| 3 | Торак бинаны ремонтлау һәм территорияләрне төзекләндерү | айга торак бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. өчен | 2,68 |
| 4 | Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту:<br><br>Сууткәргеч-канализация;<br>Газ белән тәэмин итү челтәрләре;<br>Электр белән тәэмин итү челтәрләре; | айга торак бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. өчен | <br><br>1,34<br>0,21<br>0,73 |
| 5 | Йорт яны территорияләрен карап тоту һәм җыештыру | айга торак бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. өчен | 2,71 |
| 6 | Төтен юлларын һәм вентиляция каналларын карап тоту һәм агымдагы | айга торак бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. өчен | 0,18 |

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
«___» ___________ 2019 ел,
_____ номерлы карарына
2 нче кушымта

Муниципаль торак фондының торак урынынnan файдаланган өчен (наем өчен түләү) түләү күләме

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Түләү күләме, сум |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 1. | Найм буенча база ставкасы | айга торак бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. өчен | 6,11 |